СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 29 мае № 38/11

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон (2023 елның 25 декабрендәге үзгәрешләр белән), «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 38/1 номерлы карары белән (27.05.2021 № 9/4, 16.03.2022 № 18/8, 31.05.2022 № 19/4, 13.02.2023 № 25/1, 17.08.2023 № 30/2, 09.11.2023 № 32/4 карарлары редакциясендә) расланган нигезләмәнең **13.5 статьясындагы 3 пункты һәм 13.8 статьясындагы 3 пунктының** гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 38/1 номерлы карары белән (27.05.2021 № 9/4 номерлы, 16.03.2022 № 18/8, 31.05.2022 № 19/4, 13.02.2023 № 25/1, 17.08.2023, № 30/2, 09.11.2023 № 32/4 карарлар редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәнең **8 статьясындагы 5 пунктына** түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле **унدүртенче абзац** өстәргә:

«иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмати системасында, капиталь кертемнәрне финанс

белән тәэмин итү (финанслауда катнашу) чыганагы булып федераль бюджет акчалары булган (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез милек объектларыннан тыш), капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында белешмәләр формалаштыра;

**ундүртенче абзацны унбишенче абзац** дип санарга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров